СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 10-28 «03» сентябрь 2018 ел

Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 18 декабрендәге 14-18 номерлы карары белән расланган коррупцион хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында

Коррупциягә каршы тору турындагы законнарны гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон (03.08.2018 елгы редакциядә), «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге №273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Муниципаль хезмәт турында» 25.06.2013 ел, № 50-ТРЗ Татарстан Республикасы кодексы, Мамадыш муниципаль районы Уставы нигезендә, Мамадыш муниципаль районы Советы к а р а р к а б у л и т т е:

1. Мамадыш муниципаль районы Советының 2012 елның 18 декабрендәге 14-18 номерлы карары белән расланган коррупцион хокук бозулар кылган өчен Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«коррупциячел хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсенең коррупциячел һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча доклады, анда аны башкаруның факттагы шартлары бәян ителә, һәм муниципаль хезмәткәрнең язмача аңлатмасы аның ризалыгы белән һәм коррупциячел хокук бозуны кылу фактын тану шарты белән (ышанычны югалтуга бәйле рәвештә эштән азат итү рәвешендә түләтүләр кулланудан тыш);

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Интернет-телекоммуникация

челтәрендә Мамадыш муниципаль районы http://mamadysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Мамадыш муниципаль районы Советының Регламент, законлылык, хокук тәртибе һәм депутат этикасы буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Район башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов